Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы

# КАРАР

4 декабрь,2024 ел №35

Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 сентябрендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Зур Сәрдек авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2018 елның 14 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының 2018 елның 9 ноябрендәге 29 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 40 номерлы, 2024 елның 14 июнендәге 17 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып (алга таба – Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Унберенче төркем (халык саны 1,5 меңнән 5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 20 991 |

б) 3.1 пунктының беренче абзацында «13323» санын «13990» санына алыштырырга;

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Зур Сәрдек авыл
җирлеге башлыгы Ф.М.Фәттахов